**СОВЕТ СЕЛО-АЛАТСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422721, Республика Татарстан, Высокогорский район, с.Алат, ул. Первомайская, 32

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АЛАТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

422721, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Алат авылы., Первомай ур., 32

Тел./факс 8(84365) 63-225, e-mail:Salat.Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**18.07.2022 ел.** **№ 48**

**«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алат авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» карар проектын гамәлдән чыгару хакында**

Федераль һәм региональ законнардагы үзгәрешләргә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алат авыл җирлеге Советының 2019 елның 13 декабрендәге 166 номерлы карары белән кабул ителгән «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алат авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы проектын әзерләү максатларында (Советның 07.08.2020 № 181, 04.03.2021 №17 карарлары редакциясендә), әлеге үзгәрешләрне исәпкә алып, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28, 44 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7, 20 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Алат авыл җирлеге Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Алат авыл җирлеге Советының 2021 елның 5 октябрь 33 номерлы « «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алат авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» карар проекты хакында» карарын гамәлдән чыгарырга.

2. Алат авыл җирлеге Советының 2021 елның 05 октябрь 33номерлы « «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алат авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» карар проекты хакында» карары нигезендә 2021 елның 25 октябрь 17:00 сәгатьтә түбәндәге адрес буенча: Татарстан Республикасы, Биектау районы, Алат авылы, Беренче май ур., 32 үткәрелгән гавами тыңлаулар нәтиҗәләрен гамәлдән чыгарырга.

3. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алат авыл җирлеге Советының 2019 елның 13 декабрендәге 166 номерлы карары белән кабул ителгән

««Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алат авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» (Советның 07.08.2020 № 181, 04.03.2021 №17 карарлары редакциясендә) проектын, федераль һәм региональ законнардагы соңгы үзгәрешләрне исәпкә алып эшләргә.

4. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә), шулай ук Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Совет рәисе,
Авыл җирлеге башлыгы Р.Р.Хакимуллин